ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НЫРТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

25 сентябрь 2024 нче ел №24

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 27 номерлы Нырты авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Нырты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 20 номерлы Нырты авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2025 елда – 1,2 процент; 2026 елда – 1,2 процент; 2027 елда – 1,2 процент гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларга) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган Исемлеккә кертелгән урыннарга карата.».

1.2. 2 пунктның 6 нчы пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы Т.А.Котдусов